**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 апрель № 252

г. Казань

Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле эшлеклеләр истәлеген мәңгеләштерү буенча эшчәнлекне җайга салу максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Ведомствоара комиссия) төзергә.

2. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне расларга.

3. Территорияләрендә Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерә торган монументаль һәм декоратив сәнгать әсәрләрен урнаштыру күздә тотылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге объектларны урнаштыру буенча вәкаләтләрен тормышка ашырганда Ведомствоара комиссия карарлары белән эш итүне тәкъдим итергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.Г.Шәйхразиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\252.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 26 апрель, 252 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле җәмәгать, дәүләт яки бүтән эшлеклеләр (алга таба – Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре) истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен хәл итүнең бердәм тәртибен билгеләү максатында төзелде.

2. Комиссия Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, предприятиеләр коллективлары, гражданнар керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү турында үтенечнамәләрне карап тикшерү буенча даими гамәлдә булган консультатив орган булып тора.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый акатларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссия Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен түбәндәге формаларда карап тикшерә:

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерә торган һәйкәлләр (бюстлар), стеллар, обелисклар, мемориаль такталар, истәлек билгеләре, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар кую;

физика-география объектларына, урамнарга һәм мәйданнарга, проспектларга һәм аллеяларга, торак пунктлар территорияләрендә башка шәһәр төзелеше объектларына, оешмаларга, шул исәптән мәгариф оешмаларына, шулай ук Татарстан Республикасында үткәрелә торган чараларга (фестивальләргә, конкурсларга, спорт ярышларына һ.б.ш.) Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре исемнәрен бирү;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре багышланган мемориаль музейлар булдыру, күргәзмәләр оештыру.

5. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, предприятиеләр коллективлары, гражданнар керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген

мәңгеләштерү турында үтенечнамәләрне карап тикшерү һәм Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсе буенча материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, учреждениеләрнең үзара багланышларын оештыру һәм килешеп эш итүләрен тәэмин итү;

ведомствоара чараларны оештыру;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү белән бәйле эшчәнлекне хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү материаллары буенча бәяләмәләр әзерләү өчен кирәк булганда белгечләрне җәлеп итәргә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен чакырырга;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча аңлату эшләре үткәрергә һәм җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирергә.

7. Комиссия үз вәкаләтләрен иҗтимагый башлангычларда башкара. Комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый. Комиссия составына үзгәрешләр Комиссия рәисе тәкъдиме белән кертелә.

8. Комиссия үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда түбәндәге таләпләрдән чыгып эш итә:

Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәрен Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре исемнәренә алыштыру тыела;

элек башка эшлеклеләр исемнәрен йөрткән объектларга кабат Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре исемнәрен бирү (исемен алыштыру) рөхсәт ителми;

бер административ-территориаль берәмлек чикләрендә урнашкан берничә объектка Татарстан Республикасының бер үк күренекле эшлеклесе исемен бирү рөхсәт ителми.

9. Объектлар исемнәре текстлары, алардагы язулар Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә башкарыла. Татарстан Республикасының күренекле эшлеклесе исеме бирелгән объектларның исәбен алу һәм аларны карап тоту әлеге объектлар карамагында булган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар тарафыннан башкарыла.

10. Комиссия утырышларын үткәрү вакытлары үтенечнамәләр керүгә бәйле, әмма кварталга кимендә бер тапкыр билгеләнә. Комиссия утырышында әгъзаларының яртысы катнашса, ул тулы хокуклы санала.

11. Комиссиянең Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү турында карарлары Комиссия утырышында катнашкан әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Комиссия карарлары Комиссия рәисе яисә утырышта рәислек иткән зат һәм комиссия секретары имза куйган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча аерым фикере булган Комиссия әгъзасы аны язмача бәян итәргә хокуклы. Комиссия әгъзасының аерым фикере утырыш беркетмәсенә теркәлә. Комисия утырышы беркетмәсен барлык материаллары белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы телләрен үстерү идарәсе Татарстан Республикасы Премьер-министрына тапшыра. Аерым очракларда Татарстан Республикасы Премьер-министры Комиссия карарын барлык материаллары белән бергә Татарстан Республикасы Президентына килештерүгә кертә.

12. Татарстан Республикасы Премьер-министры килештермәгән очракта Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр коллективлары һәм граждannar мөрәҗәгатен кабат карап тикшерү бер елдан соң гына рөхсәт ителә, мөһим әһәмияткә ия булган яңа шартлар барлыкка килгән очраклардан тыш.

13. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы телләрен үстерү идарәсе гамәлгә ашыра.

---

F:\KARAR\2017\252-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 26 апрель, 252 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Шәйхразиев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Комиссия рәисе |
| Савельев Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы телләрен үстерү идарәсе башлыгы, Комиссия секретары |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Водопьянова Татьяна Павловна | Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе (килешү буенча) |
| Волкова Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гәрәев Раил Рузәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкче урынбасары – Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы |
| Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкләрне өйрәнү институты директоры (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |

| | |
|---|---|
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иштирәкев Хәбир Газиз улы | Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасының Республика советы рәисе (килешү буенча) |
| Калинкин Денис Геннадьевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Лаврентьев Александр Петрович | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшмәкәрләре ассоциациясе» төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе президенты, «Казан вертолет заводы» ААҖ директорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы секретары (килешү буенча) |
| Мостюков Илдус Шайхелислам улы | «Татарстан геройлары» иҗтимагый берләшмәсе рәисе (килешү буенча) |
| Сәлахов Мәкъзум Халимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Хәкимов Рафаил Сибгат улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗәни исемендәге тарих институты директоры (килешү буенча) |
| Шакиров Минсәгыйт Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы рәисе (килешү буенча) |
| Юлашев Әхәт Гайнулла улы | Татарстан Республикасы Сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары (инвалидлары) иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча). |

F:\KARAR\2017\252-3.docx